РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

24 июль 2023 ел №197

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы җирле үзидарә органнарының
муниципаль хезмәткәрләрен бүләкләү турындагы
нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакына түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге № 149 Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставына таянып Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен бүләкләү турындагы нигезләмәне» кушымта нигезендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен һәм бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләрен бүләкләү турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2023 елның 02 июнендәге № 185 карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә әлеге карар нигезендә эш итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) (pravo.tatarstan.ru.) һәм

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 01 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне район Башлыгы урынбасарына һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советының 2023 елның 24 июлендәге
№197 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен бүләкләү турында
**НИГЕЗЛӘМӘ**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1 Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә премияләр түләү тәртибен һәм шартларын билгели, муниципаль хезмәткәрләрнең эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген, җирле үзидарә органнарына йөкләнгән вәкаләтләрне үтәгән өчен аларның җаваплылык дәрәҗәсен күтәрү, башкарыла торган бурычларның сыйфатын күтәрү, вазыйфа инструкциясендә каралган вазыйфаи бурычларны вакытында һәм намуслы үтәү максатларында. Әлеге Нигезләмәдә премияләрнең түбәндәге төрләре каралган:

- Җирле үзидарә көненә, Татарстан Республикасы көненә багышланган премия;
- Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре спартакиадасында катнашучыларга премия

1.2. Муниципаль хезмәткәрләргә премия түләү Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башлыгының хокукый акты нигезендә җирле үзидарә органы җитәкчесе боерыгы белән рәсмиләштерелә.

**2. Җирле үзидарә көненә, Татарстан Республикасы көненә багышланган премия**

2.1. Җирле үзидарә көненә, Татарстан Республикасы көненә багышланган премия бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү булып тора, агымдагы сметада хезмәткә түләү фонды экономиясе булганда, финанс елына бюджетта расланган план күрсәткечләреннән артык бюджетны үтәгәндә фактик алынган керемнәр һәм агымдагы финанс елы башына барлыкка килгән район бюджеты счетындагы калган акчалар булганда, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджетының финанс-икътисадый торышыннан чыгып абсолют күләмдә (рубльдә) яки бер акчалата тәэмин итү күләмендә билгеләнә ала.

**3. Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре спартакиадасында катнашу нәтиҗәләре буенча премия**

3.1. Муниципаль хезмәткәрләр Спартакиадасында актив һәм нәтиҗәле катнашкан өчен команданың һәр катнашучысына аерым спорт төре өчен акчалата премия күләмен билгеләргә:

1-нче урын – 10 000 сум;
2-нче урын - 7000 сум;
3-нче урын - 5000 сум.

Муниципаль хезмәткәрләр спартакиадасы нәтиҗәләре буенча гомумкоманда урыны өчен:

1-нче урын -15 000 сум;

2-нче урын -10 000 сум;

3-нче урын - 5000 сум.

Премияләр агымдагы сметада хезмәткә түләү фонды экономиясе булганда, финанс елына бюджетта расланган план күрсәткечләреннән артык бюджетны үтәгәндә фактик алынган керемнәр һәм агымдагы финанс елы башына барлыкка килгән район бюджеты счетындагы калган акчалар булганда, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджетының финанс-икътисадый торышыннан чыгып түләнә.